| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.11.2021 ел Баулы шәһәре № 195/1

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 28 декабрендәге «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын тотрыклы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 485 номерлы карарына (2020 елның 21 декабрендәге 241 номерлы карар белән ертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү һәм Баулы муниципаль районы территориясендә сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү исәбенә терлекчелек продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 28 декабрендәге «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын тотрыклы үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 485 номерлы карарына (2020 елның 21 декабрендәге 241 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программада (карарга 1 нче кушымта):

- «Программа паспорты» I бүлегендә «Программаны финанслау чыганаклары» юлындагы 2 нче багана эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны гамәлгә ашыруга финанс чараларына ихтыяҗ 1 186 100,00 сум тәшкил итә, шулардан 2019 елда - 461 100,00 сум, 2020 елда - 367 500,00 сум, 2021 елда - 357 500,00 сум (җирле бюджет акчалары).

Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында була һәм тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;

- Программага 2 нче «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тотрыклы үстерү» муниципаль программаның төп чаралары исемлеге” 2 нче кушымтасында:

«Сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзүдә матди ярдәм күрсәтү» 1.2 пунктында:

- җиденче баганада «357,5» саннарын өстәргә;

- сигезенче баганада «138,6» санын «496,1» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров